Актаныш муниципаль районы Башлыгына

## Актаныш муниципаль районында 2019 елның беренче кварталы өчен гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау нәтиҗәләре турында

2019 елның беренче кварталында муниципаль район Башлыгы һәм Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетына 55 мөрәҗәгать керде, шуларның 12се интернет-кабул итү һәм электрон почта аша алынды.

Муниципаль район Башлыгына һәм Башкарма комитетка гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләрнең тематикасы, нигездә, халыкның социаль һәм икътисади хәленә кагылышлы сораулар белән тәкъдим ителә: торак шартларын яхшырту, коммуналь-көнкүреш хезмәте күрсәтү, экология, капиталь төзелеш, халыкны социаль яклау, медицина хезмәте күрсәтү, мәгариф, социаль яклау проблемалары.

Барлык кергән мөрәҗәгатьләрне түбәндәге категорияләргә бүлеп бирергә мөмкин:

| № | Гражданнар мөрәҗәгатьләре төрләре | Мөрәҗәгатьләр саны | % |
|---|---|---|---|
| 1 | Җир буенча сораулар | 4 | 7,3 |
| 2 | Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау | 5 | 9 |
| 3 | Икътисад, сәнәгать | 4 | 7,3 |
| 4 | Төзелеш, архитектура һәм торак шартларын яхшырту | 19 | 34,5 |
| 5 | Мәгариф, фән, мәдәният һәм спорт | 14 | 25,4 |
| 6 | Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек | 4 | 7,3 |
| 7 | Сәламәтлек саклау | 2 | 3,6 |
| 8 | Коммуналь хезмәтләр | 3 | 5,4 |
| | **БАРЛЫГЫ** | **55** | 99,8% |
| 9 | Уңай җавап бирелгән, гражданнар мөрәҗәгатьләре саны | 10 | 18 |
| 10 | Аңлатмалар бирелгән, гражданнар мөрәҗәгатьләре саны | 45 | 81,8 |
| | **БАРЛЫГЫ** | **55** | 99,8% |

Гражданнар тарафыннан төзекләндерелгән торакка хокукны гамәлгә ашыру иң кискен һәм социаль әһәмиятле проблемаларның берсе булып кала. 2019 елның беренче кварталында торак мәсьәләләре өлеше 34,5% тәшкил итте.

2019 елның беренче кварталында мәгариф белән бәйле мәсьәләләрнең артуы күзәтелә (14 мөрәҗәгать). Бу, барыннан да элек, югары уку йортларына юллама алу мәсьәләсе.

Каты өслекле юлларны карап тоту, ремонтлау һәм төзү белән бәйле мөрәҗәгатьләр, автобус маршрутлары мәсьәләләре актуаль булып тора. Алар узган елдагы кебек үк кала бирә (2019 елның беренче кварталында -19 мөрәҗәгать)

Халыкны социаль яклау Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты эшчәнлегенең мөһим аспекты булып тора. Социаль яклау учреждениеләренең эше һәр конкрет кешегә максималь якын, аның проблемаларын хәл итүгә юнәлдерелгән. 2019 елның беренче кварталында Актаныш муниципаль районы Советына һәм Башкарма комитетына эшкә урнашу, ташламалар бирү, матди ярдәм күрсәтү мәсьәләләре белән бәйле 5 мөрәҗәгать керде. Соңгы еллар дәвамында әлеге мәсьәләләр буенча мөрәҗәгатьләр саны даими булып кала бирә.

Гражданнарны кабул итү графигы расланды. Халык өчен муниципаль район Башлыгы, аның урынбасары, Башкарма комитет җитәкчесе, аның урынбасарлары, структур бүлекчәләр башлыклары гражданнарны шәхсән кабул итә. Бердәм кабул итү көне — сишәмбе. Кирәкле документлар (шәхси кабул итү карточкалары яки кайбер бүлекчәләрдә журналлар) законнар нигезендә рәсмиләштерелә. Бүлек җитәкчеләре урынбасарлары кабул итүне сишәмбе көннәрендә генә түгел, кирәк булганда алдан язылмыйча да алып баралар. Гражданнарны күчмә кабул итүләр, район җитәкчеләренең халык белән даими очрашулары, «кайнар линия», муниципаль район Башлыгының интернет-кабул итү бүлмәсе эшли.

Кергән барлык мөрәҗәгатьләр контрольгә алынды. 18% (10) мөрәҗәгать уңай хәл ителде.

Азакта шуны билгеләп үтәсе килә, безнең уртак эшебезнең соңгы нәтиҗәсе - район халкына аларның мөһим проблемаларын хәл итүдә ярдәм итү. Һәм бу эшнең халыкның күңелендә аңлау һәм җавап табуы бик сөендерә. Районда үткәрелә торган чаралар халыкны битараф калдырмый. Җирле үзидарә органнарына тәнкыйть белән мөрәҗәгать итүчеләр саны арту белән беррәттән, рәхмәт сүзләре булган мөрәҗәгатьләр дә шактый килә.

Гомуми бүлек җитәкчесе Л.Г.Хәйдарова